**МИНИСТЕРСТВО ПО ДЕЛАМ МОЛОДЕЖИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯШЬЛӘР ЭШЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**24.05.2019** **№162**

Казан ш.

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының 13.09.2018 елдагы 24нче санлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 18нче ноябрендәге 906нчы санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы министрлыгы, Дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы Иҗтимагый совет турындагы типлаштырылган нигезләмәгә үзгәрешләр кертелү белән бәйле рәвештә боерам:

1. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының 13.09.2018 елдагы 24нче санлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктының дүртенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

2.2 пункт түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«җәмгыятьтә коррупцион тәртипкә түемсезлек формалаштыру.»;

5.12 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.12. Иҗтимагый совет карары буенча Иҗтимагый совет утырышына башкарма органнар, коммерцияле булмаган оешмалар, фәнни учреждениеләр вәкилләре, экспертлар, башка белгечләр һәм гражданнар чакырылган булырга мөмкин.».

2. Дәүләт хезмәте, кадрлар һәм юридик эш секторына әлеге боерыкны Татарстан Республикасы юстиция Министрлыгына дәүләт теркәвенә җибәрергә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны үз артыннан калдырам.

**Министр** **Д.И.Фәттахов**